**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы**
**Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советы**

**КАРАР № 10**

**Урыссу ш.т.п.** **« 14 » 07 2020 ел**

***Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу шәһәр тибындагы поселогының 2014 елның 21 ноябрендәге "Физик затлар милкенә салым турында" №20 карарына үзгәрешләр кертү хакында***

Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарына туры килүгә бәйле рәвештә һәм Татарстан Республикасы Ютазы районы прокуратурасының 2020 елның 30 июнендәге 02-08-01 номерлы протесты нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советының 2014 елның 21 ноябрендә кабул ителгән «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» гы №20 Карарына түбәндәге үзгәреш кертергә:

3.1 пункттагы “Салымнан азат итү салым органнарына ел саен раслый торган документларны тапшырганда бирелә” текстын “Салымнар һәм җыемнар турындагы законнарда билгеләнгән салым ташламаларына хокуклы физик затлар салым ташламасы бирелү турында үз сайланышлары буенча гариза тапшыра, шулай ук салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслаучы документларны тапшырырга хокуклы.»

2. Әлеге карар аны рәсми бастырып чыгарган көннән башлап, Интернет мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендәге http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, http://jutaza.tatarstan.ru веб-адресы буенча муниципаль районның рәсми сайтында Интернет мәгълүмати - телекоммуникацион челтәрендә урнаштырылганнан соң һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы территориясендә махсус мәгълүмат стендларында урнаштырылганнан соң үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Урыссу шәһәр тибындагы**
**поселогы Башлыгы урынбасары** **Р. М. Гарипов**